# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы**
**Урыс авыл җирлегенең Тулбай торак пунктында**
**үзара салым кертү турында**

**27 ноябрь 2023 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Тулбай торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1«Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлегенең Тулбай торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә 2024 елда үзара салым кертергә, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылганнар, 1 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, биш һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдән, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш.
2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1.Тулбай авылында Сабантуй уздыру урыны территориясен төзекләндерү (өстәлләр, эскәмияләр әзерләү һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

2. Тулбай авылында юлларны грейдирлау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

3. Тулбай авылында авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)

3.Җыен нәтиҗәләрен Урыс авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Минзәлә муниципаль

районының рәсми сайтында бастырырга http://menzelinsk.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan. кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль районы
Урыс авыл җирлеге башлыгы _______________ И.С. Аксюкова
(имза)

Совет УРУСОВСКОГО сельского поселения
ОГРН 1021605552880
р 06-117/09
ИНН 1628002805